КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 апрель г.Казань № 541

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2022 ел, 1 сентябрь, 942 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2022 ел, 1 сентябрь, 942 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2023 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен;

2023 елга төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бу карар белән расланган социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре барлык милек рәвешләрендәге һәм ведомство буйсынуындагы мәгариф оешмаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары, эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары, урта звено белгечләре әзерләү программалары, бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары буенча белем алучы укучыларга кагыла дип билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган 2023 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәренең 1 һәм 2 пунктындагы 2 графасында «Белем бирү оешмасын» сүзләрен «Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга 2023 елга төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 1 сентябрь, 942 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 28 апрель, 541 нче
карары редакциясендә)

2023 елга төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре

| Т/с | Социаль ярдәм төрләре буенча түләүләр исеме | Төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча укучыларга социаль ярдәм төрләре буенча түләүләр күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманы тәмамлаганда ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга бер тапкыр бирелә торган пособие | 899 |
| 2. | Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманы тәмамлаганда ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган пособие | 59 337 |
| 3. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга уку әдәбияты һәм язу өчен кирәк-яраклар сатып алуга ел саен бирелә торган пособие | 3 210 |
| 4. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен ел саен бирелә торган пособие | 25 289 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 5. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга туклану өчен ай саен бирелә торган пособие | 7 877 |